БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

«27» 09 2023 ел

№ 251

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 255 номерлы карары белән расланган алдан килештерү нигезендә җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4.1 пунктының өченче абзацында «45 көннән дә артмаган» сүзләрен «35 көннән дә артмаган» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.8.3.2 пунктының 6.2 пунктчасында:

а) «а» пунктчасында «әгәр Җир кодексында һәм махсус сакланылучы табигый территорияләр турында Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә;

б) «н» пунктчасында «беренче һәм икенче поясларда» сүзләрен «беренче пояста» сүзләренәалмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле «о» пунктчасы өстәргә:

о) «табигый дәвалау ресурсын саклауның санитар (тау-санитария) округының беренче зонасы чикләрендә»

1.3. 7 нче кушымтада:

а) 32 пунктта «әлеге күчемсез мөлкәт объектлары бирелгән» сүзләрен «муниципаль милектә булган биналар, корылмалар арендага бирелгән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 41 пунктта «бакчачылык» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 256 номерлы карары белән расланган торглар үткәрмичә генә җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2.8.2.1 пунктының 6.2 пунктчасында:

а) «а» пунктчасында «әгәр җир кодексында һәм махсус сакланылучы табигый территорияләр турында Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә;

б) «н» пунктчасында «беренче һәм икенче поясларда» сүзләрен «беренче пояста» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле «о» пунктчасы өстәргә:

о) «табигый дәвалау ресурсын саклауның санитар (тау-санитария) округының беренче зонасы чикләрендә»

2.2. 8 нче кушымтада:

а) 23 пунктта «әлеге күчемсез мөлкәт объектлары бирелгән» сүзләрен «муниципаль милектәге биналар, корылмалар арендага бирелгән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 32 пунктта «бакчачылык» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 6 нчы октябрендәге 320 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. 1 нче кушымтада:

а) 16 пунктта «әлеге күчемсез мөлкәт объектлары бирелгән» сүзләрен «муниципаль милектәге биналар, корылмалар арендага бирелгән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 22 пунктта «бакчачылыкны» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару» сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.2 пунктчасының һәм 2 пунктындагы 2.1 пунктчасының "в" пунктчасы 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Галимуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
Җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов